# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге составына керүче Урман Асты Шонталасы авылы

13ноябрь 2019 ел. № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге составына керүче Урман Асты Шонталасы торак пунктында гражданнар җыены

**Карар итте**:

1. 2020 елда Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге чараларга юнәлдерергә:

-җирлек эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау;
- торак пунктларда урамнарны яктыртуны карап тоту;
- су насосы сатып алу;
- МТЗ -82.1 тракторына ягулык-майлау материаллары сатып алу;
- ДПО гаражын ремонтлау;
- халыкның ял итү урыннарын төзекләндерү;
- җирләү урыннарын төзекләндерү.

3.Әлеге карарны Урман Асты Шонталасы авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге Советы бинасының мәгълүмат стендында урнаштырырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге башлыгы А.Ә.Җиһаншин